

**Гүзәлия Габдрахман кызы Исмәгыйлева** – татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Эшләгән еллары: 1968-2003

**Дәүләт бүләкләре, исемнәре**: ТАССРның Атказанган мәктәп укытучысы, 1991нче ел;

“Яшь буынны укытуда һәм тәрбияләүдә ирешкән уңышлары өчен” Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, 1998 нче ел.

**Гүзәлия Габдрахман кызы Исмәгыйлева** -1948 нче елның 10 октябрендә Салагыш авылында туа. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлагач, татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып Исәнбай мәктәбендә 1968 нче елдан эшли башлый. 1971- 76 нчы елларда, читтән торып, Казан дәүләт педагагогия институтын тәмамлый.

Гүзәлия Габдрахмановна чирек гасырдан артык авыл балаларына туган телебез серләрен, бай әдәбиятыбыз тарихын өйрәтте. Ул милләтебезне, телебезне киләчәк буыннарга саклап калу өчен бөтен белемен, тырышлыгын, искиткеч бай тәҗрибәсен кулланган. Дәресләрне мавыктыргыч, җанлы итеп уздыру өчен бик күп эзләнгән, укыган, башкалар тәҗрибәсен өйрәнгән.

Гүзәлия Габдрахмановна, үз Һөнәренә тугрылыклы, аңа чын күңелдән бирелгән педагог буларак, коллективка эшкә килгән яшь укытучыларның гына тугел, гомүмән, районыбыз мәктәпләрендәге ана теле укытучыларының да яраткан остазы иде. Ул берничә ел бу фән укытучыларының район берләшмәсен җитәкләгән.

“Һәр әдәбият дәресе яңалык алып килергә, укучының иҗади көчен, белемен арттырырга, рухи дөньсын баетырга тиеш”,- ди Гүзәлия Габдрахмановна. Аның тормыш принцибы - укучыларына үрнәк булу . Ул кыенлыклар алдында югалып калмый, тормыш давылларын җиңеп, үз

дигәненә ирешә, кешеләр белән һәрвакыт аралашып, тормышның ямен табып яши.

*Рәхмәт Сезгә  Гүзәлия апа!*

*Тормыш! Син нинди матур һәм катлаулы! Матур, чөнки кешегә бәхет китерүче, күңел тынычлыгы бирүче Хезмәт бар. Матур, чөнки кешеләрнең җаннарын сафландыручы Җыр- Моң, Китап бар. Матур, чөнки иң авыр чакларда, адашкан юл күрсәтүче Дуслык бар. Матур, чөнки һәр кешенең яшәргә- Туган җире, сөйләшергә – Туган теле, иркәләнергә –Әнисе, әниседәй якын күрүче, әдәплелеккә, зыялыкка, кешелекле булырга өйрәтүче һәм белем бирүче кадерле Укытучысы бар!*

*Мин кечкенәдән үк укытучы булырга хыялландым. Бу хыялыма өмет чаткыларын Сез кабыздыгыз, Гүзәлия апа! Ниһаять, минем дә балачак хыялларым чынга ашты: хәзер мин Яр Чаллы каласында Сезнең кебек татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшлим.*

*Дәресләр үткәргәндә, һәрвакыт күз алдымда Сезнең якты сүрәтегез килә, колагымда ягымлы тавышыгыз яңгырый. Исәнбай урта мәктәбендә укыган чагымда ук мине Сез, яраткан укытучым Исәгыйлева Гүзәлия Габдрахман кызының, тирән белемлелеге сокландыра иде. Сез безне һәрвакыт якты йөз белән каршы аласыз, чишмә челтерәведәй ягымлы тавышыгызны тыңлаган саен тыңлыйсы килә.*

*Институтта укыганда да мина Гүзәлия апам кул астында практика үтәргә туры килде. Ул мине киңәш, ярдәм сорап килгән чакларымда беркайчан да кире бормады. Үз мәшәкатьләре дә башыннан ашкан булуга карамастан, сабыр гына тыңлап, тормыш авырлыкларын җиңеп чыгарга өйрәтте.*

*Күңелемдә татар теле- газиз анам теленә мәхәбәт уятканыгыз өчен, сабыр, гадел булырга өйрәткәнегез өчен бик зур рәхмәт Сезгә, Гүзәлия апа!*

Гөлназ Исмәгыйлева.